| | | |
|---|---|---|
| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧУРАКАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ<br><br>423746, Чуракай авылы, Совет ур., 69 йорт | | СОВЕТ ЧУРАКАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br><br>423746, село Чуракаево, ул. Советская, дом 69 |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**10.12.2025 ел** **№ 8**

**«Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге Советының 2023 елның 27 марты 4 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарә рәисләренең, рәис урынбасарларының, контроль-хисап органнары аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 24.04.2018 № 281, 14.06.2018 № 481, 17.10.2018 № 940, 29.12.2018 № 1320, 17.11.2021 № 1087, 13.12.2021 № 1222, 17.09.2022 № 1015, 30.04.2024 № 290, 24.06.2024 № 451, 25.09.2024 № 829, 14.04.2025 № 228 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр), Актаныш муниципаль районының Чуракай авыл җирлеге Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Чуракай авыл җирлеге Советының «Актаныш муниципаль районының Чуракай авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2023 елның 27 март 4 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «15 389» саннарын «16 928» саннарына алмаштырырга;

күрсәтелгән карарга 3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Чуракай авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **Р.Р.Хайдаров**

Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге Советы карарына 27.03.2023 ел, № 4
3 нче кушымта (Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге Советы 10.12.2025 № 8 карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль берәмлек башлыкларының, депутатларының, авыл җирлекләрендә даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәре**

| Вазыйфа атамасы | Айлык акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) | | |
|---|---|---|---|
| | авыл җирлекләрендә | | |
| | 10 төркем | 11 төркем | 12 төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 27 601 | 25 401 | 23 201 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 20 565 | 18 254 | 16 931 |
| Депутат | 16 928 | 16 928 | 16 928 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 16 928 | 16 928 | 16 928 |